**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

24.04.2015 ел № 59/5

**«Әҗмәкәй авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләренә бәяләрне билгеләү тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы, «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль милектә булган җирләрнең бәясен исәпләү мәсьәләсе буенча җирле үзидарә органнары һәм җир кишәрлекләре сатып алучылар арасында барлыкка килә торган җир мөнәсәбәтләрен җайга салу максатларында Тукай муниципаль районы Татарстан Республикасы районы, шулай ук муниципаль милектән нәтиҗәле файдалану максатларында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Әҗмәкәй авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләренә бәяләрне билгеләү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми порталында, газетада бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.Г. Фазылҗанов